**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «25» февраленнән № 48

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 278 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 278 номерлы карарына (2024 елның 27 ноябрендәге 297 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.2., 1.3., 1.4., 1.5 пунктчаларында «58 сум» сүзләрен «69.43 сум, шул исәптән субсидияләрне исәпкә алып, җирле бюджет акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 пунктның 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3 гаиләнең бер әгъзасына җан башына уртача керем Татарстан Республикасы буенча билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк туры килгән аз керемле гаиләләрдән булган укучылар, аз керемле гаиләләр арасыннан 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаилә балалары өчен бәясе 69,43 сумлык, шул исәптән субсидияләрне исәпкә алып, җирле бюджет акчалары исәбеннән, бушлай кайнар иртәнге ашлар оештырырга;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов